| ГЛАВА<br>Кучуковского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Көчек авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2025 Түбән Көчек авылы № 1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районы « Көчек авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегенең Түбән Көчек
торак пунктында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм
алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законның 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Түбән Көчек торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 31октябрендә 10сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Түбән Көчек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, (I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, иреклеләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә

яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан) башка), 2026 елда үзара салым акчасын 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган  мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, кулланугa ризамы?

1) Түбән Көчек торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Яңа урам, Колхоз тыкрыгында 9нчы йорттан 11нче йортка кадәр юл салу өчен таш алу һәм җәю, автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

2) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су  башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Буадан Калинин урамына су агызу торбалары сатып алу һәм урнаштыру, су башняларынтоту һәм хезмәт күрсәтү, насос будкасына ремонт һәм торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар);

3) Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электротоварлар сатып алу һәм урам  яктырткычларын урнаштыру, электрикка хезмәт хакы түләү, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

4) Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (янгын сүндерү машинасы тоту; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

5) Һәйкәлләр кую һәм аларның янәшә-тирәсен төзекләндерү (Ленин урамында Тыл хезмәтчәннәренә һәйкәл эшләтү һәм куйдыру.

6) Торак пунктны төзекләндерү

-Түбән Көчек торак пункты юлларын кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәт килешүе буенча трактористка хезмәт хакы түләү;

- кыргый куаклыклар, агачларны эшкәртү һәм бетерү өчен гербицидлар сатып алу;

- авария хәлендәге һәм корыган агач-куакларны кисү, чүп үләннәрен чабу;

-МТЗ-82 тракторы тоту һәм хезмәт күрсәтү, башка чыгымнар.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Түбән Көчек авылы, Ленин урамы, 12нче йорт, авыл клубы адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлегенең башкарма комитетына җыенны оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе ,
Авыл җирлеге башлыгы А.Р.Төхфәтуллина